**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 16 июль № 483

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2016 – 2018 елларга Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарына халыкның тормыш сыйфатын һәм аларның эшчәнлеге нәтиҗәлелеген бәяләү индикаторлары буенча идарә итүгә дәүләт йөкләмәсен раслау турында» 2016 ел, 2 март, 129 нчы карары белән расланган 2016 – 2018 елларга Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарына халыкның тормыш сыйфатын һәм аларның эшчәнлеге нәтиҗәлелеген бәяләү индикаторлары буенча идарә итүгә дәүләт йөкләмәсенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2016 – 2018 елларга Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарына халыкның тормыш сыйфатын һәм аларның эшчәнлеге нәтиҗәлелеген бәяләү индикаторлары буенча идарә итүгә дәүләт йөкләмәсен раслау турында» 2016 ел, 2 март, 129 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 12 апрель, 214 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган 2016 – 2018 елларга Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарына халыкның тормыш сыйфатын һәм аларның эшчәнлеге нәтиҗәлелеген бәяләү индикаторлары буенча идарә итүгә дәүләт йөкләмәсенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

«Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы» бүлегендә:

2 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| «2 | Татарстан Республикасы буенча уртача эш хакына карата Татарстан Республикасы территориясендә гражданнарга түләүсез медицина ярдәме күрсәтүнең дәүләт гарантияләре программасында катнаша торган предприятиеләр һәм оешмаларның уртача эш хакы (узган елның шул ук чорына карата), процент | еллык | х | х | х | х | х | ≥100 | ≥100 | ≥100»; |

3 нче пункт үз көчен югалткан дип санарга;

«Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы» бүлегенең 1 нче пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| «1 | Татарстан Республикасы буенча гомуми белем бирү өлкәсендә уртача эш хакына карата субсидияләр ала торган дәүләткә карамаган мәгариф предприятиеләре һәм оешмаларының уртача эш хакы (узган елның шул ук чорына карата), процент | еллык | х | х | х | х | х | ≥100 | ≥100 | ≥100»; |

«Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы» бүлегенең 3 нче пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| «3 | Татарстан Республикасы буенча уртача эш хакына карата Татарстан Республикасында Социаль хезмәтләр белән тәэмин итүчеләр реестрына кертелгән дәүләткә карамаган оешмаларның уртача эш хакы (узган елның шул ук чорына карата), процент | еллык | х | х | х | х | х | ≥100 | ≥100 | ≥100»; |

«Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы» бүлегендә:

1 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| «1 | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 ел, 30 апрель, 6-700 нче | квартал | | | | | | | | |

| | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | боерыгы нигезендә министрлыкка (ведомствога) беркетелгән предприятиеләрнең гомуми санында зыянга эшли торган предприятиеләр өлеше, процент, шул исәптән: | | | | | | | | | |
| | сәнәгатьтә (икътисадый эшчәнлек төрләренең гомумроссия классификаторы (ОКВЭД) буенча: файдалы казылмалар чыгару, эшкәртүче производстволар, электр энергиясе, газ һәм су җитештерү һәм бүлү) | | 24,1 | 23,0 | 26,6 | 26,0 | 25,5 | 25,0 | 24,0 | 23,0 |
| | сәүдәдә | | 16,9 | 19,0 | 19,8 | 19,5 | 19,0 | 19,0 | 18,0 | 17,0»; |

12 нче һәм 13 нче пунктларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| «12 | Татарстан Республикасы вәкиллеге булган илгә Татарстан Республикасыннан продукция экспорты арту, процент | еллык | x | x | x | x | x | 80 | 85 | 90 |
| 13 | Татарстан Республикасы вәкиллеге тәкъдиме буенча төп яки өстәмә белем алу өчен Республикага килә торган чит ил студентлары һәм белгечләре саны арту, процент | еллык | x | x | x | x | x | 70 | 90 | 100»; |

«Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы» бүлегенең 2 нче пунктындагы 3 графага «квартал» сүзен өстәргә;

«Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы» бүлегенең 1 нче пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| «1 | Кече предприятиеләр, шул исәптән микропредприеләр, һәм индивидуаль эшмәкәрләр җитештерә торган продукция (хезмәтләр) әйләнешенең үсеш темпы, процент | еллык | 101,2 | 103,2 | x | x | x | 102,1 | 103 | 104»; |

«Татарстан Республикасының Инвестицион үсеш агентлыгы» бүлегенең «Дәүләт-хосусый партнерлык һәм хосусый инвестицияләр өлкәсендә инвестицион

эшчәнлекне үстерү белән идарә итү (01.18)» бүлекчәсенә түбәндәге эчтәлекле яңа $2^1$ нче пункт өстәргә:

| | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| «$2^1$ | «Чаллы» алга киткән социаль-икътисадый үсеш территориясенең җәлеп ителгән резидентлары саны (арта барган нәтиҗә белән), берәмлек, шул исәптән: | | | | | | | | | |
| | эре проектлар | еллык | x | x | x | x | x | 4 | 10 | 20 |
| | кече һәм урта проектлар | еллык | x | x | x | x | x | 6 | 41 | 100». |

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
вазыйфаларын башкаручы А.В.Песошин